# ЙӨЗҮЧЕ ЕФИМОВАНЫҢ ТРЕНЕРЫ КАЗАНДАГЫ ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫНДА МЕДАЛЬЛӘР АЛУГА ӨМЕТЛӘНҮЕН БЕЛДЕРДЕ

30.07.2015, 08:23
СПОРТ

**Россия йөзүчесе Юлия Ефимованың шәхси тренеры Дэвид Сало белдергәнчә, Казандагы Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионатында спортчы кыз уңышка ирешергә өметләнә.**

Чәршәмбе көнне йөзү буенча АКШ җыелма командасы Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионатында катнашу өчен Казанга килде. Йөзү буенча ярышлар 2-9 август көннәрендә “Казан Арена”да узачак. Ефимова Калифорниядә Сало җитәкчелегендә күнегүләр белән шөгыльләнә.

*“Минемчә, ул стартка абсолют әзер. Ул бик яхшы күнегүләр уздырды, соңгы стартларда үзен бик әйбәт күрсәтте. Монда да югарыда калыр дип уйлыйм. Билгеле инде, без медальгә өметләнәбез! Без һәрвакыт медальгә өметләнәбез”, - диде Сало.*

Материал "Р-Спорт"/"Россия сегодня" ХМА редакциясе тарафыннан әзерләнде

Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА